Көлү – сихәт, көлеп яшәү мәслихәт!

ISSN 0136-7110

Чаян



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ ФЕВРАЛЬ * 2022 * КАЗАН

2



Сергей АНДРИАНОВ

Рашат НИЗАМИ

ПУШКИН КАЗАНДА

Әйтерләр: Пушкин бар, Пушкин бар...
Сибгат Хәким

И-и, хәзрәти Пушкин! Нигә әле
Казаннарның юлын сайладың?
Чөнки Казан бер дә яратмаган
Уй-фикернең түбән, сай чагын.

Әби патша мәгәр белде микән
Шагыйрь ничек атта җилдергән...
Каретаның тәгәрмәчләренә,
Уралышып,
Кыпчак даласында җил йөргән.

Патшалардан, канлы державадан
Синең җаның, рухың өстәрәк, –
Каурый каләм, ак кәгазең белән
Хакыйкатьне бардың өстерәп.

Иң катлаулы, кискен чорларда да
Декабристлар яклы булдың син.
"Аксөякләр" дигән исемлекне
Халыкчанлык якка бордың син.

Ә халыкмы? Сәнәк тотсаң гына –
Хакыйкатькә таба юл ачык.
Шуңа да бит тарих әргәсендә
Калкып чыккан фетнә Пугачев.

Пугачевның эзе чакыргандыр,
Ил картларын эзләп килгән ул.
Ә Казанның – шагыйрьләр каласы
Икәнлеген, шиксез, белгән ул.

Ашыгып кына килгән сентябрьнең
Гәрәбәгә баткан чаклары.
...Ярты Рәсәйне чорнап алган
Пугачёвның яугир сафлары.

Татар полковниклары да – шунда,
"Бунтовщик"ны алар яклаган.
Алар, алар – бердәм сафка басып,
Азатлыкка таба атлаган.

Күз яшьләре һәм алсу кан белән
Сугарылган илнең яртысы.
Рәсәй киңлегендә дуэль барган:
Яхшы белән яман тартышы.

Печән базарына таба карый
Фукс яшәгән йорт тәрәзе.
(Пушкин кебек, шушы йортка килеп,
Иман яңартырга кем әзер?)

Акыл тәпәнендә ми урнына
Коры кибәк булса, мондыйлар –
Патшалар һәм власть каршысында,
Күмәкләшеп, койрык болгыйлар.

Хатынына хатлар яза Пушкин:
"Юкка йөрмәдем мин Казанда, –
Пугачёвның кайнар эзләреннән
Азык таптым үземә, язарга..."

Михаил ЛАРИЧЕВ





ШОМБАЙ болай диде...

Хөрмәтле Чаян! Суд утырышларыннан хәбәрләр белән танышып, бездәге хөкем итүнең үзенчәлегенә гаҗәпләнәм. Кайчагында "мөстәкыйль һәм салкын акыллы" хөкемдарлар шундый карарлар чыгаралар – исең китәр! Кибеттән бер төргәк бәдрәф кәгазе чәлгән өчен төрмәгә утырырга мөмкин, ә бюджеттан миллиардлар урлаган өчен, нишләптер, берни дә булмый...

О. ХӘЙРУЛЛИН

ЯШЕЛ ҮЗӘН

– Үзегез уйлап карагыз: урланган ул кәгазь белән бүлешкән өчен кем дә булса сезне ирекккә чыгарырга риза булыр микән? – диде Шөмбай ага, укучыбызның хатын укып чыккач.

Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ

ТАМГАЛЫ–ТАМГАСЫЗЛАР

Элек малга һәм дә колга
Тамга салган түрәләр.
Бүген исә ку-ар-кодлар
Өләшеп көн күрәләр.

Тамгалы вә тамгасызга
Куйдылар безне бүлеп.
Тамгалылар йөри булыр
Тамгасызлардан көлеп.

Тамгасызлар әйтерсең лә
Мәдәниятсез кыргый.
– Тамгаң юк икән – гафу ит,
Беркая кереп булмый!..

Тамгаң юк икән – тамгалы
Җәмгыятьтә урын тар.
Илдә шундый уен бара...
Белмим, кайсыбыз отар?

Тамгасызлар кавеменә
Аерды безне язмыш.
...Әҗәлең җитсә – һәркемгә
Җир тигез, – ике карыш...

Александр АЛЁШИН





Александр ШУЛЬПИНОВ

ШИКЛЕ ТӘВӘККӘЛЛЕК

Тәвәккәллек, билгеле булганча, яхшы нәрсә. Ләкин уңай максатка юнәлтелгән булса, әлбәттә. Чөнки шикле кыюлык та бар, мәсәлән, аның коррупция белән бәйлесе. Ул очракта югарыда утырган түрә, үзенең кылган кыек эшләренең киң җәмәгатьчелек һәм махсус органнарга билгеле булмаячагына ышанган хәлдә, законга төкереп карый. Һәм бөтен тормышын – репутациясен, карьерасын, гаилә иминлеген, ә кайчагында үз ирекен дә куркыныч астына куя. Кыскасы, бер йотым шәраб авыр махмырга әверелеп куя... Укучылар игътибарына төрле вакытта коррупциягә каршы политика мәсьәләләре буенча белгечләр юлыккан бернича вакыйга тәкъдим итәбез.

ИКЕ УРЫНДЫКТА

Берьюлы ике урындыкта утыру – бик уңайсыз нәрсә. Ә кайчагында хәвефле дә – җимерелеп төшүең дә мөмкин. Алабуга үзәк дәваханәсендә шулай да бу әйберне үзләрендә сынап карарга тәвәккәллек кылганнар. Монда өч дистәдән артык табиб "ике урындыкта утырган": алар үз поликлиникаларын ташламыйча гына "Медикам" шәхси клиникасы белән хезмәттәшлек иткәннәр. Уңайлы бит – тугандашлар шул ук бинада урнашкан. Дәваханәнең баш табибы исә гомумән "Медкам"ның директорлар советы әгъзасы да булып торган. Түләүле хезмәтне, баш ватып тормыйча гына, район поликлиникасы аппаратурасында күрсәткәннәр. Гади итеп әйткәндә, дәүләт милкен эшмәкәрлек максатында файдаланганнар. Мондый уңайлы хәлдә, әлбәттә, "Медкам" тиз арада район дәваханәсенә җитди конкурент булып киткән. Түләүле профилактик тикшерүләр вакытында, мәсәлән. Ә бит бу эшчәнлектән килгән акча район медицина оешмасының кассасын тулыландыра алыр иде. Шикле тәвәккәллекнең дәүләт интересларына каршы килүе шул буладыр инде!

ГАИЛӘ ТУРИЗМЫ

Шул ук Алабуганың балалар-яшьләр туризмы үзәге директорының хәләл җефете кибет ачып җибәргән. Килешенү буенча ул 47, 7 квадрат метр арендалаган, ә чынлыкта исә ике тапкыр күбрәк мәйдан файдаланган. Өстәвенә, сәүдә ноктасы коммуналь түләүләр белән баш ватмаган – ут, су, җылыту һ. б. өчен Үзәк түләп барган. Директорга бу гына аз тоелгандыр, күрәсең – ул фиктив рәвештә хатынын һәм кызын эшкә урнаштырган. Әйтергә кирәк, Алабугада мондый хәл сирәк күренеш түгел – шәһәрдәге балалар спорт мәктәбе директоры шулай итеп дүрт кешене "эшкә алган". Аларның "хезмәте" спорт мәктәбенә 1,4 миллион сумга төшкән...

Нәтиҗәдә нәрсә? Биш ел эчендә Үзәкнең аренда буенча гына югалткан табышы миллион сумнан артык булып чыккан. Ә "гаилә туризмы" директор өчен җинаять эшенә әверелгән.

ШАКШЫ ЧИСТАРТУ КОРЫЛМАСЫ

Кеше яшәгән һәрбер шәһәр-авыл өчен чистарту корылмаларының ни дәрәҗәдә мөһим булуын сөйләп торуның кирәге юктыр. Бу экология дә, чисталык та һәм төбәкнең гомуми культура күрсәткече дә. Теләчедә андый корылмалар бар – алар бернича ел элек 26,7 миллион сумга төзелгәннәр иде. Ләкин алар һаман эшсез тора. Кешенең тормыш эшчәнлеге продуктларыннан арынуы монда элеккечә – ассенизатор машиналары ярдәмендә башкарыла.

Районга кирәк объект нигә хәзерге вакытка кадәр эшләмичә тора соң? Тикшерүчеләр бу сорауга җавапны тапкан – аның төзелеше вакытында коррупциягә бәйле вакыйгалар булган икән. Бу нинди җан өшеткеч вакыйгалар соң? Заманында район тырышлыгы белән төзелеш һәм җиһазлаштыру эшләрен җирле башкарма комитет җитәкчесе урынбасары учредитель булып торган "СФ "Строитель" акционерлык җәмгыятенә йөкләгәннәр. "Тугандаш" фирма тарафыннан корылмаларның төзелеп бетмәвенә карамастан, Теләче түрәләре аны кабул итәргә булганнар. Ә тиздән төзелеш эшләренә һәм сатып алынган җиһазларга тотылган акчаның тиешеннән 11,7 миллион сумга артыграк булуы ачыкланган. Эшне башкаручы, төгәлрәк әйтсәк, башкармаучы бу суммадан 110 мең сумны гына кайтарып, үзен банкрот дип игълан иткән. Хуҗасыз калган корылма әлегәчә эшсез тора, тик шулай да ассенизатор машинасы сирәк-мирәк ташландык объектның мәйданында "бушанып" киткәли...

ГАРАЖ КОНЦЕРТМЕЙСТЕРЫ

Уйлап карыйк: фәкыйрь һәм мәңге акча кытлыгыннан иза чиккән культурадан нәрсә алып була икән? Бу мәсьәләгә ничек караудан тора! Әлки мәдәният бүлегендә баш катырып тормаганнар – район мәдәният йортына концертмейстер урынына башына музыка турында уй кереп тә чыкмаган бер бәндәне "эшкә" алганнар. Ә "музыка белгече" исә тыныч кына үз гаражында машиналар ремонтлау белән шөгыльләнгән. Рояльне фортепьянодан аера белмәгән останы ничек итеп иҗат кешесенә әйләнүе турында сорагач, ул исе дә китмичә: "Миңа нәрсә... Мәдәният бүлеге мөдиренең машина йөртүчесе эшкә урнашу өчен документларымны сорап алды..." – дип җавап биргән.

Бәлки Әлки мәдәният әһелләре гараж концертмейстеры ярдәмендә культура бүлегендә балансста торган бер дистә чамасы ватык машинаны рәткә кертмәкче булганнардыр? Юк... Алар бөтенесе дә кузгалмаган килеш хезмәткәрләрнең ишегалларында тора. Алар өчен ел саен транспорт салымы түләнеп бара. Ә "концертмейстер"га законсыз рәвештә түләнгән 400 мең сумның эзләре өзелә...

Менә шундый культурасыз вакыйга!

Тәвәккәллек вакыйгаларын
Дамир ИСМӘГЫЙЛЕВ өйрәнде.







Казан тарихыннан

РИШВӘТЧЕЛЕК ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

Рәсәйдә ришвәтне һәрвакыт биргәннәр һәм алганнар. Ләкин XIX гасырның беренче яртысында ул шулкадәр таралган күренешкә әйләнгән ки, аның турында хәтта китаплар да барлыкка килгән. Кагыйдә буларак, бу – сатирик әсәрләр булган. Еш кына авторлары күрсәтелмәгән бу китаплар кулдан-кулга йөреп тузып беткәннәр. Шундый киң популярлык казанган басмаларның берсе – 1830 елда басылып чыккан "Ришвәт алу сәнгате. Вафат булган титуляр советник Тяжалкин кәгазьләре арасында табылган кулъязма". Бу данлыклы китапның авторы Казан морзасы, чиновник һәм әдип, Герцен нәшер иткән "Колокол" журнылының яшерен авторы, Пушкин, Боратынский һәм Вяземский белән якыннан таныш Эраст Петрович Перцов булган.

Үзенең сатирик әсәрендә ул "хөкүмәтнең кискен чаралары нәтиҗәсендә ришвәт алу сәнгатенең таркалыш хәленә килүе" хакында борчыла, һәм укучыга чиновник Тяжалкинның ришвәтнең төрләре һәм җаваплылыктан котылу ысуллары турында киңәшләр белән "лекцияләр" тәкъдим итә.

Авторның күзәтүләре буенча, ришвәт өч төргә бүленә: "Беренчедән, натура белән; бу төргә сыйлаулар, дуслык һәм мәхәббәт хөрмәтенә бүләкләр, истәлекле көннәрдә законлы рәвештә акча түләмичә милек сату һ. б. керә".

Акчадан гади ис килми – хуш ис аңкыта! Ришвәтнең икенче төре – затлы тәңкәләр һәм күңелгә җылы биреп шыгырдаучы кәгазь акча белән. «Бөтен тәкъдим ителүче дәүләт акчасыннан ассигнацияләрне сайлагыз, чөнки алар кулдан-кулга тавышсыз, тын гына күчәләр, аларны җиңел генә алтын йә көмешкә алыштырып була, урынны күп алмыйлар һәм кесәгә, галстук артына, итек кунычына урнаштырып була..."

Һәм ниһаять, өченче төр – ришвәтнең иң югары, затлы төре. «Аның белән иң югары һәм асыл затлар файдалана: бу бер-береңә рәхмәт йөзеннән ярдәм кулы сузу..."

Үзенең "ришвәтчелек энциклопедиясендә" автор судларның оста итеп җаваплылыктан котылып калып, "гаделлек эзләү юлындагы кешеләрнең кесәләрен бушатуы" турында сөйли. Хакимияттә утыручы каракларны мәңге туйдырып торучы казна турында да. Дәүләт заказларын бүлгәндәге "откатлар" турында да...

Күргәнебезчә, коррупция гөмбәзе астында бер яңа нәрсә дә юк. Әгәр "Ришвәт алу сәнгате"нең авторы китабын ачыктан-ачык ирония белән язмаган булса, ул бүгенге ришвәтчеләргә дәреслек була алыр иде..

Әйтергә кирәк Эраст Петровичның гомере күңелсез тәмамлана: сатирик әсбап авторы 68 яшендә "акча эшләренең тәмам таркалуы нәтиҗәсендә" үз теләге белән тормыштан китә. Ришвәт алмаган, күрәсең...

Камил ФӘТХУЛЛИН

Абау!

ОЗЫН-ОЗАК

Казанда Фучик урамындагы тугыз катлы йортта яшәүчеләр өч ел инде үз йортларына кем хезмәт күрсәтәчәген билгели алмый. Фатир хуҗаларының бер өлеше ТСЖны икенче идарәче компаниягә алыштырырга телиләр. ТСЖ тарафдарлары аларның оппонентлары – түләмәүчеләр, дип раслый һәм «хакимият алмаштырганда» коммуналь хезмәтләр өчен бурычларын юкка чыгарачаклар дип исәплиләр. Әмма «озын гомерлеләр»нең мондый финалы килеп чыкмаячак: закон буенча, компанияне алыштырган вакытта язын чистартылмаган кар кебек бурычлары юкка чыкмый.

ЭШЛӘҮЧЕ ХӘЕРЧЕ

ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының йомгаклау коллегиясендә гаҗәп фактны игълан иткәннәр. Пенсионерларның хәерчелек чигендә нибары 8%, ә ярлыларның 40% ы эшкә яраклы, өстәвенә, аларның 67% ы көн саен эшкә йөри икән. Хәерчеләрнең күпчелеге гади бер яки ике балалы гаиләләр.

МАЙМЫЛ ХЕЗМӘТЕ

Чаллы приставлары автокалада яшәүче берәүнең бер миллионлы бурычы турында документларны югалтканнар. Кәгазьләрне өч елга якын торгызырга маташалар, шул вакыт эчендә бурычлы кеше вафат була. Тик бурыч хисабына тапшырылган фатирны исәпкә алмыйча, башкарма эш кабат кузгатылган. Федераль суд приставлары хезмәте идарәсе хезмәткәрләре дүрт елга якын бу эш өстендә тырышып эшләгәннәр, гадәттә, кабул ителгәнчә, ЗАГС органнарыннан запрос ясата белмәгәннәр.


КОШ СТРЕССЫ

Чаллыдагы зоокибетнең берсеннән тутый кошны урлаганнар. Бер җинаятьче сатучының игътибарын читкә юнәлдергән арада, икенчесе читлек белән кошны эләктергән. Тиздән каракларны полиция тоткарлаган, алар заказ буенча эш иткәннәр. Кош зыян күрмәгән һәм элеккеге урынына кайтарылган. Тик кичергән стресс барыбер дә эзсез узмаган. Хәзер тутый кош бертуктаусыз чыркылдый – әллә кайтуына сөенә, әллә кичергәннәрен сөйли.









ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР

Әгәр дә кеше иртән йөгерергә теләми икән, аны бернәрсә дә туктата алмый.

• • •

Гөнаһ ияләре көзге шикелле – аларда бездә яшеренеп утырган начар эшләр чагыла.

• • •

Җәмгыятьтә эшсезлек арткан саен, яңа дәүләт бәйрәмнәре барлыкка килә тора.

• • •

Җүләр – ахмак сүзләр сөйләгән кеше түгел, ә моны үзе сизмәгән кеше.

• • •

Яманат яулау өчен чибәр һәм аралашучан булу җитә – калганын кешеләр уйлап чыгарыр һәм башкаларга сөйләр.

• • •

Сәясәтчеләр үзләре өчен нотык яза белмиләр, ә кайчагында укый да алмыйлар.


• • •

Тормышта уңышка ирешү өчен ахмак булу гына җитми, тәрбияле дә булырга кирәк.

• • •

Кайчагында очып китәр өчен, бераз артка чигенергә кирәк.

(акыл ияләре мәҗлесендә язып алынды)









ЧАЯН ШИФАХАНӘСЕ

Игорь КИЙКО





Василий АЛЕКСАНДРОВ

ГИППОКРАТ ШАЯРТУЛАРЫ

• Медиклар фикеренчә, безнең юллар шифалы: бөсерне дә урынына кертә, бөердәге ташларны да чыгара!

• Авыру табибның каравына мохтаҗ, һәм ул никадәр ерактанрак караса, шулкадәр яхшырак...

• Ашыгыч ярдәм никадәр соңрак килсә, диагноз шулкадәр төгәлрәк була...

• Тарих фәнендәге «безнең эрага кадәр» төшенчәсе белән пандемия башлануга кадәр вакытны билгеләргә вакыт җиткәндер...

• Дөньяда яңа авыру төре барлыкка килде: симптомсыз авырулар. Элек бу «сәламәт булу» дип атала иде.

• • •


– Доктор, мин бәдрәфкә йөри алмыйм.
– Иң мөһиме – күңелегезне төшермәгез! Бәдрәфкә йөри алмасагыз, театрга, күргәзмәләргә йөрегез...

• • •

– Доктор, миндә импотенция!
– Керосин эчегез!
– Ярдәм итәр дип уйлыйсызмы?
– Җанкисәгем, ул бит самолётлар күтәрә!



Виктор ФЁДОРОВ



Михаил ЛАРИЧЕВ

ЗӨЛФӘТНЕҢ ТУУЫНА – 75!



Вячеслав БИБИШЕВ шаржы.

Зөлфәт – узган гасырның татар шигърияте күгендә иң күренекле шәхесләрнең берсе. Аның шигырьләреннән фикерләү масштаблылыгы, көрәш рухы, кайнар хис ташкыны ургып тора.

Зөлфәтнең иҗади мирасы – ул ил гаме белән яшәгән шагыйрьнең тормыштан аерылгысыз күңел тарихы. Түбәндә китерелгән юлларны шуның ачык дәлиле дияргә буладыр.

ЯЛГЫЗ САНДУГАЧ

Безнең өскә гүя ниндидер көч
Авыр, кара йолдыз кабызды –
Өер-өер ач бүреләр улый,
Һәм сандугач сайрый – ялгызы...

Тәкъдирме бу?
Явыз ихтыярмы?
Безнең утны кемнәр сүндерде? –
Үз нәҗесе белән уйный Ватан.
Барып җиттек –
Ватан тилерде.

Үксүеме, сайравымы – белмим,
Әллә инде җанын юата –
Котырган ил сандугачы сайрый
Япа-ялгыз гына куакта.

Кара гарасатлар кайнаганда
Нинди зәгыйфь бу өн, нинди саф!
Җиһан үзе җимерелер сыман,
Шул сандугач тик бер ялгышса...

Туплaндылар кыргый өерләргә
Адәм балалары юлларда.
Шулай уңайлырак ботарларга,
Шулай уңайлырак уларга.

Күзләр – куздай!
Сырт йоннары торган!
Тешне кычыттыра мең афәт –
Портретың шушы,
Яңа заман,
Шушы, бәндәм, безнең кыяфәт.

Шул булырмы соңгы сурәтебез
Безнең – сөя белгән халыкның?
Син кайлардан килдең, кара йолдыз?
Нигә безнең күктә калыктың?

Ач өерләр туеп ял итәрләр,
Ырылдашып җирдә җан кыйгач,
Һәм шуларны ярлыкауны сорап,
Өзгәләнер ялгыз сандугач...

1992

Антон МАКУНИ

Тере энциклопедия

Ул аны парк эскәмиясендә күреп алды һәм шунда ук гашыйк булды. Ул, тирә-юньдәге смартфоннарына текәлеп утыручылардан аермалы буларак, калын китап укып утыра иде. Бу аңа бик ошады – ул буш карашлы җилбәзәк кызларны өнәми иде. Ул янәшәгә килеп утырды һәм җиңелчә генә аның терсәгенә кагылып китте. Кыз елмаеп куйды. Ул үзе дә чибәр иде һәм кызга ошады. Кыз китабын култык астына кыстырды, һәм алар кечкенә сукмак буйлап киттеләр. Егетнең күңелендәге бөтен бар нәрсә белән бүлешәсе килә иде...

– Кара, – диде ул һәм күктәге иң якты йолдызга төртеп күрсәтте, – нинди матур!

Кыз карап алды да:

– Кече Аю йолдызлыгы, икенче зурлыктагы йолдыз, 15 миллиард ел, төньяк юнәлешен күрсәтә...

Нәрсә дип җавап бирергә белмичә, ул күктә йөзеп баручы ноктага күрсәтте.

– Бу нәрсә – йолдыз атылдымы әллә?

– Бу самолёт! Ту-154. Туполев конструкторлык бюросында эшләнгән, моторларының көче... утыру урыннары... – кыз төгәл саннар атады.

Ул бөтенләй югалып калды. Һәм шул чакта каршыларына бер кош килеп кунды.

– Кара, нинди гүзәл кошчык! – диде ул.

– Чәперчек, – дип билгеләде кыз, кошка карап алып, – чыпчыклар төркеменнән. Озынлыгы 16–18 сантиметр, Евразиядә, Африкада, Төньяк Америкада 11 төре яши. Бик файдалы – зарарлы бөҗәкләрне ашый...

Кызның җилкәсенә күбәләк килеп кунды.

– Кара, – дип кычкырды ул, – нинди матур күбәләк!

– Әйе, күбәләк, – диде кыз һәм күбәләкне җилкәсеннән бәреп төшерде. – Көн күбәләкләре гаиләсеннән, җәелгән канат киңлеге 2–4 сантиметр, ике меңнән артык төре бар...

Башы әйләнеп китүгә карамастан, егет аягында торып калды.

– Сизәсеңме, нинди исерткеч хуш ис!

– Бу – ясмин, – дип ярып салды кыз, башын да бормыйча, – зәйтүннәр гаиләсеннән куак, 200 төре бар, декоратив үсемлек буларак файдаланыла, парфюмериядә кулланыла...

Ул, һушыннан язып, җиргә ауды. Кыз шунда ук үзалдына әйтеп куйды: "Һуштан язу – кыска вакытлы тамырлар тонусының төшүе... Билгеләре – кинәт хәл китү, күңел болгану, баш әйләнү..."

Аннан соң кискен борылды да, үкчәләрен шакылдатып, китеп барды...



Мирзаһит тормышыннан

СУДАГЫ БАЛЫК

Җәй. Көн кичкә авышып килә. Эш вакыты ахырына якынлашкан. Пилорамадагы ирләр әкрен генә өйләренә җыена – инструментларын җыя, киемнәрен кага. Мирзаһит кына, берни булмагандай, станок янында маташа. Өйрәнчеге Васыйф – хирыс балыкчы, аның тирәсендә бал корты кебек бөтерелә:

– Мирзаһит абый, күпме эшләргә була инде, өйгә кайтырга вакыт бит!

– Ә кая ашыгырга? Станок бит ул үз-үзен ремонтлый алмый, – ди Мирзаһит, ачкычы белән нидер бора-бора.


– Беләсеңме, – ди Васыйф, – мин балык тозлап куйган идем... Аны тизрәк асып куярга кирәк!

– Синең балыгың – тозлыкта, ә минеке – суда – алай да корт чаккандай сикеренмим бит, – дип җавап бирә Мирзаһит.


– Ничек инде суда? – дип гаҗәпләнә Васыйф. – Аны бит тизрәк тозларга һәм асып куярга кирәк, әрәм булуы бар бит!

– Алай иткәнче, аны әле тотарга кирәк. Ул Идел суында бит! – дип җавап бирә Мирзаһит югалып калган ярдәмчесенә.

Зөлфәт ШАҺИӘХМӘТОВ



Василий АЛЕКСАНДРОВ



Валерий ТАРАСЕНКО

БЕР ФИКЕРГӘ – ИКЕ КАРАШ

Рашат Низами: Замана гына түгел, аның хәтта җилләре дә үзгәрде – агачларны ега, түбәләрне куптара, өермәләр пароходны йота.

Алмаз Хәмзин: Чирләре дә үзгәрде – кешеләрне кыра, иманнарын, нәфесләрен котырта, бер сүз белән әйткәндә – юләрләнде дөнья...

Р. Н.: Стоматолог юк. Борынгы кешеләр теш сызлауга ничек түзде икән? Әллә...

А. Х.: Әллә аларның булуыннан уңдыкмы?.. Нишләсәләр дә акча суыралар – яматсаң да, алдырсаң да, куйдырсаң да кесәңне чистарталар. Гомумән, авызда теш беткәнче түзәбез...

Р. Н.: Рәсәйнең сәяси "кыланышлары"ннан соң, илдә милли мәсьәлә, әче камыр сыман, кабарганнан-кабара бара...

А. Х.: Мәсәрә һәм мукләнә башлагач тәртипкә килә ул.

Р. Н.: Кеше үзенең ничек тууын, ничек йокыга китүен хәтерләмәс, диләр.

А. Х.: Бурычларын хәтерләсә, шул ярый инде...

Р. Н.: Кешенең күңел төпкелендә кояш булса, ул – коеп куйган оптимист!

А. Х.: Ай булса – пессимист буламы?..

Р. Н.: Гаҗәп – су коенганда яисә мунча кергәндә бөтен кешеләр, ничектер, бертигез (!) күренә...

А. Х.: Кайбер җирләрен исәпкә алмаганда...

Р. Н.: Бокс – бер хәл, тормышта үзе белән үзе сугышучылар да байтак лабаса.

А. Х.: Кайберәүләр сугышмыйча дуслашмый – бу, син әйткән очрак та, үзүзен тану була инде.

Р. Н.: Өчпочмак, пәрәмәч – милли була, ләкин Менделеев таблицасы берничек тә милли була алмый.

А. Х.: Ул хәтта халыкныкы да түгел хәзер – олигархларныкы.

Р. Н.: Ахмак кеше дә үзен акыллыга санап йөрергә бик мөмкин.

А. Х.: Алар хәзер по-го-лов-но!

Р. Н.: Матур сөйләп уңышка ирешәләр, ямьсез сөйләп хатага абыналар.

А. Х.: Бездәге өстә утыручы "каргалар" да хәзер матур сайрыйлар, ләкин эшләре "каркылдау" гына булып кала.

Р. Н.: Чалыш көзгеләр булган кебек, тормышта чалыш хакыйкатьләр дә чагылгалый.

А. Х.: Шулай ук по-го-лов-но!



Вячеслав ШИЛОВ



Игорь КИЙКО



• • •

– Әгәр халык кинәт кенә тәмәке тартуын ташласа, хөкүмәт нишләр иде?

– Аракыга акциз күтәрер...

– Әгәр дә аракы эчүне дә ташласа?

– Сәламәт яшәү рәвешенә салым салыр иде...

• • •

– Әти, машинамның тәгәрмәче тынын җибәрде...

– Ә син нигә миңа шалтыратасың? Ирең бар бит, шуңа шалтырат!

– Шалтыраттым, телефонын алмый...

– Запастагысы бардыр бит?

– Аңа да шалтыраттым, ул да җавап бирми...

• • •

– Җәяү йөрү сәламәтлеккә файдалы.

– Алай булгач, нигә машина сатып алдың?

– Җәяү йөри торган җиргә барып җиту өчен.

• • •

Мин менә нәрсә уйладым әле. Дикторлар, ИГИЛ турында сөйләгәндә, һәрвакыт өстәп, Рәсәй җирлегендә тыелган, дип әйтәләр. Ә ришвәт турында сүз чыкса, бернәрсә дә өстәмиләр. Бәлки, бөтен эш-хикмәт шундадыр?

• • •

Табибларга һәм укытучыларга бүләк алуны тыйдылар. Аллага шөкер, ниһаять илдә ришвәтчелеккә чик куелачак.

• • •

– Бабай, ни өчен армиядә портянкаларны куллану тыелган?

– Улым, хәзерге заман призывнигы өчен бу нәрсә артык катлаулы гамәл...

• • •

Корпоративка барлык хатын-кызлар матур итеп киенеп, бизәнеп килгәннәр, ә ирләр – гадәттәгечә. Моннан нәтиҗә ясарга була – ир-атлар һәрвакыт пөхтә һәм матур.

• • •

Үзеңә исән чакта һәйкәл куйсаң, аны исән чагыңда ук җимереп ату ихтималы күпкә артачак.

• • •

Түрә тендер откан фирмага килә дә:

– Нигә сез акчаны урладыгыз, ә юлны салмагансыз?

– Әти, җитәр инде кыланырга.



БУЛДЫКСЫЗ ТАЛАУЧЫ

Екатеринбургның үзәгендә билгесез бәндә Сбербанк бүлекчәсен таларга тырышып караган. Талаучы: "Әгәр шартларымны үтәмәсәгез, барыгызга да эләгәчәк", – дип куркытып, хезмәткәрләрдән акча таләп иткән. Әмма тегеләре куркып калмаганнар, якасыннан тотып, аны урамга төртеп чыгарганнар. Банкка зыян килмәүгә һәм барча хезмәткәрләрнең исән-сау калуына карамастан, полиция булдыксыз талаучыны җитди сөйләшү өчен эзли.

МӨМКИНЛЕКТӘН ФАЙДАЛАНЫП

Мәскәүдә Эчке эшләр министрлыгының тикшерү бүлеге башлыгы урынбасары бераз акча эшләмәкче булган. Ул камерада тотылучы берәүнең телефонын конфискацияләгән һәм шунда ук смартфондагы 17 мең сумны үзенә күчергән. Ләкин бу акча аз тоелган, һәм ул тоткарланган гражданин исеменә тагын 250 мең кредит алырга маташып караган. Әмма тоткын ир куркаклардан булып чыкмаган, һәм шома тикшерүче турында эчке иминлек хезмәтенә гариза язган. Хәзер җиңел акча сөюче үзе рәшәткә артында суд карарын көтеп утыра.

СӘЕР СЫННАР


Чиләбенең баш архитекторы Павел Крутолаповка шәһәрне бизәгән өчен эләккән. Җирле елга ярында сәнгать әсәре сыйфатында ялып торган өч кит сыны урнаштырганнар. Калада яшәүчеләр шунда ук сораулар яудыра башлаганнар: нигә шул гади генә нәрсәгә 9,7 миллион сум тотылган, диңгез җәнлекләренең шәһәр елгасына нинди мөнәсәбәте бар? Хакимиятка тикшерү үткәрергә туры килгән. Бизәү әйберенең бәясе аларда сорау тудырмаган, ә менә өч китның шәһәргә матурлык өстәмәве белән түрәләр ризалашканнар һәм архитекторга выговор чәпәгәннәр.

ТҮЛӘҮЛЕ БҮЛӘК

Коми Республикасында Бөек Ватан сугышы ветераны, 98 яшьлек Мария Урасиновага узган ел Җиңүнең 75 еллыгына тантаналы рәвештә бүләк тапшырганнар. Ә быел олы яшьтәге хатынга салым инспекциясеннән бүләк өчен налог түләргә "чакыру кәгазе" килеп төшкән. Ветеранның балалары әниләренең кәефен кырмас өчен, аңа әйтмичә генә тиеш сумманы үзләре түләгәннәр. Коми буенча Федераль салым хезмәте Идарәсендә барысы да закон буенча, дип аңлатканнар. Әгәр бүләк бюджет акчасыннан булса, аның өчен салым алмыйлар, ә бу очрактагы кебек, башка оешманы тарткан булсалар, бүләк алган ветеран дәүләткә бурычын кайтарырга тиеш икән.



Игорь КИЙКО



Анастасия ВАСИЛЬЕВА



Михаил ЛАРИЧЕВ



Гүзәл СӘНГАТУЛЛИНА

Ишек катында

Нәсимә Пенсия фондының ишегеннән атлап керде. Аның каршысына дежур администратор килеп чыкты:

– Ни йомыш белән йөрисез? Сезне чакырдылармы?

– Юк, чакырмадылар, – дип җавап кайтарды Нәсимә. – Минә пенсия яшенә килеп җитәм, шуңа килдем, сорашырга, белешергә...

– Пенсия яшенә? Иртәрәк түгелме соң? – дип сорап куйды администратор хатын.

– Озакламый миңа 55 тула.

– Сез, нәрсә, пенсия яшен арттырганнарын ишетмәдегезме әллә? Вакыт уздырып йөрисез. Сездән башка да эш җитәрлек монда!

Нәсимә бераз югалып калды. Аннары бар көчен җыеп:

– Сезнең эшегез безгә пенсия санарга дип билгеләнгән түгелме соң? Пенсия яшен артканын беләм. Әмма ләкин иртәрәк тә чыгып булганын ишеттем. Шуңа килдем. Стажым җитәрлек дип уйлыйм.

– Димәк, пенсиягә иртәрәк чыкмакчы буласыз инде... Ә сез, гафу итегез, кем булып эшлисез? Җырчымы, балеринамы? Әллә танылган берәр артистками?

– Юк, мин гади эшче. Гомерем буе завода эшләдем. Халык арасында танылган булмасам да, үз эшемне намус белән башкардым.

– Андыйлар күп хәзер, бер сез генә түгел. Барыгызны да пенсиягә иртә чыгара башласалар, безнең фондның акчасы җитеп бетмәс.

– Күптән түгел генә ишеттем, бер җырчы, әле 44 яшендә генә булса да, пенсиягә чыккан.

– Дөрес. Җырчыларның эшләре бик авыр бит. Гомер буе сәхнәдә, халык каршында. Аларга за вредность положено!

– Нинди вредность инде ул, сәхнәдә сикереп? Менә мин гомерем буе заводта, авыр эштә эшләп, вредность ала алмадым.

– Нинди?

– Ә менә шундый!..

– Билетлар сатыламы, халык ничек кабул итә, продюсерлар ярдәм итәме. Ул бит, беләсезме, нервларны ничек бетерә. Шуңа күрә аларга иртә чыгарга рөхсәт ителә дә. Ә сез... Шул бер станокта эшләп, зарплатагыз баргандыр. Шулай булгач, аптыратып йөрмәгез, тагын биш елдан килерсез!.. – дип төгәлләде сүзен администратор.

Нәсимә, ни әйтергә белмичә, чыгып китте.

– Менә бит халык нинди көнчә. Ишеткәннәр, имеш, иртә пенсиягә чыкканны. Җырчы булырга иде... – дип, артыннан мырлап калды администратор.



ҮТКӘННӘРГӘ КАРЫЙК КАЕРЫЛЫП

Үзенең йөз елга якын тарихы дәверендә «Чаян» кемнәрдән генә көлмәде икән. Төрле елларда аның үткен кыскычларына империалистлар һәм сугыш чукмарлары да, карак түрәләр һәм бюрократлар да, спекулянтлар һәм аферистлар да, эчкечеләр һәм хулиганнар да эләкте...

Шулай да «Чаян»ның иң «яраткан» персонажлары ришвәтчеләр булды. Алар турында күпме үткен карикатуралар, чәнечкеле фельетоннар булгандыр – санап бетергесез! Ә алар һаман исән-сау һәм үзләрен бик яхшы тоялар. Ул гына түгел, вак ришвәтчеләрдән эре коррупционерлар булып үстеләр – вакыты да үзгәрде бит...

Заманында «Чаян»ның ул яманнан ничек көлгәнен бу биттә күрерсез.




Н. КОМАРОВ, 1958



Б. СТАРЧИКОВ, 1961

– Кул җылыта!..



И. ХАНТИМЕРОВ, 1960



Э. ГЕЛЬМС, 1963

– Ә моны нәрсә белән майларга икән?



В. КОСМЫЛИН, 1980

– Гаризагызда нәрсә анда?



В. ФЕОКТИСТОВ, 2008









В. ИГНАТЬЕВ, 1963



• • •

Кызларның – сезнең каршыга, ә кайчагында артыгыздан йөгергәнен да телисезме? Сезне теләсә нинди һава шартларында түземсезлек белән көткәннәрен телисезме?

АТП автобус йөртүчеләрне эшкә чакыра!

• • •

Чынлыкта 2021 ел бигүк начар булмады. Тиздән сез моңа үзегез дә ышанырсыз.

• • •

– Апчихи!
– Сәламәт бул!
– Апчихи!
– Күрәм, син мине беренче мәртәбәсендә аңламадың бугай!

• • •

– Сез шундый зифа. Диетадамы?
– Зарплатада.

• • •

Табиб авыруны тынычландыра:
– Дулкынланмагыз. Сезгә бернинди дә куркыныч янамый. Мин үзем дә сезнеке кебек чир белән авырдым.
– Ләкин бит сезнең табибыгыз икенче булган...

• • •

Хатын-кыз чәчтараштa:
– Мин башымны тәртипкә китерергә телим!
– О-о, бу мәсьәләд белән сез психиатрга барыгыз.

• • •

Институтта имтихан биргәндә:
– Сезнең җавап – «дүртле»лек.
– Профессор, ләкин бит мин «бишле» өчен түләдем.
– Инфляция, җанкисәгем.

• • •

Автосервиста:
– Двигательдә ят тавышлар ишетмәдегезмени?
– Юк, мин бүген беренче мәртәбә хатынсыз килдем.

• • •

Ике түрә:
– Мондый платин сәгать кайдан алдың?
– Коррупционда.





• • •

Берәү цирк директоры янына килеп керә:
– Минем сезнең өчен программам бар, өйрәтелгән хайваннар. Бегемот фортепьянода уйный, жираф җырлый!
– Чынмы?! Күрсәтегез хәзер үк!

Бегемотны кертәләр, рояль китерәләр. Бегемот утыра да уйнап җибәрә. Янына жираф килеп баса да җырлый башлый.

– Менә сиңа мә! Бу бит искиткеч! Килешенү төзибез! Дөньяның иң шәп циркларында – гастрольләр! Ә шулай да әйтегезче, сез моны ничек эшлисез?!

– Моның сере бик гади. Иске фокус! Эш шунда ки, бегемот үзе уйный да, җырлый да. Ә жираф авызын гына селкетеп тора.



КЫЙММӘТЛЕ ТАНЫШУ

Кадерле "Чаян"! Һәр бала Теш феясының төшкән теш өчен ярыйсы гына матур бүләкләр китергәнен белә. Менә без дә үземнең 4 яшьлек кызым белән шундый феяны таптык, ләкин ул шактый гына акча таләп итә икән. Балабызның теше сызлый башлады да без "Дент-А-Мед" түләүле клиникасына киттек. Горький юлына чыккандагы әлеге дәвахәнә стоматологы, баланы карагач, беренче кабул итүдә үк дәваламаячагын әйтте – бу докторның бала белән танышуы гына булган һәм терапия планын әзерләү процедурасы. Тиз арада тагын алты сөт тешен дәваларга кирәк булачагын искәртте. Шунысы кызык: әле мохтаҗлык беленмәсә дә... Ә менә авырта торган тешен ул иң соңыннан дәвалый башлаячак икән – ике айдан соң. Аның эше бик күп, янәмәсе. Шул арада, сорап та тормыйча, фея баланың тешләренә гигиена чистартуы үткәргән һәм дә фторлаган, аннан соң безне кайтарып ук җибәрде. Безгә шушы эшләре өчен 3 меңгә якын акча түләргә туры килде. Ә кызым һаман шул сызлаган теше белән интегә. Докторның мондый сәер планы белән теш дәвалау безгә 50 меңгә төшәчәге көн кебек ачык. Мөгаен, бу танышлык безнең кесәгә бик нык сугачак...

М. ВӘЛИЕВА

КАЗАН

ПАРЛАНГАН КҮЗЛЕК

Хөрмәтле редакция! Бүген штрафны теләсә нәрсә өчен эләктерергә мөмкин – сәбәбе генә чыксын! Миңа, мәсәлән, парланган күзлегем өчен гаеп тактылар. Кемнеке ничек инде, минеке, әгәр битлекне борынга каплап тартсаң, күзлегем шундук томанлана. Салкын һавадан кибеткә кергәндә битлегемне аз гына аска төшергән идем, бик уяу сакчылар минем гамәлемнән "гафу итмәслек" закон бозу күреп, протокол язарга тотындылар. Алар өчен минем сиксәненче дистәне ваклап яшәүче икәнем аклануга сәбәп түгел иде. Ә күзлексез мин бер адым да атлый алмыйм. "Ваши проблемы!" – дип кенә җибәрделәр.

Бер атнадан Госуслуги сайтына миңа мең таңкәлек штраф килгән иде. Суд карарында минем гаебем аклануымдагыча – томанланган күзлек аркасында дип күрсәтелгән. Димәк, картайган көнемдә җәмәгать тәртибен бозучы булып чыкканмын.

В. НИКИТИН

БАЛЫК БИСТӘСЕ районы

Александр ШУЛЬПИНОВ



Илдар НӘФИЕВ



ТАТМЕДИА


ТАТМЕДИА ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАРЫ ҺӘМ ОТКРЫТКАЛАРЫ — МАРКЕТПЛЕЙСЛАРДА

WILDBERRIES


kazanexpress


OZON


Маркет



16+



АНЫҢ ИҖАТЫ ТУРЫНДА КАЛӘМДӘШЛӘРЕ

Яратам мин бу малайның шигырьләрен, өметем зур ул егеткә. Мин аңарда иҗат кешеләренә иң кирәкле сыйфат – тынгысызлыкны күрәм. Җаны тынгысыз аның, яшьлеккә хас бунтарьлыгы да бар. Бик әйбәт. Яшь чакта бунтарьланмагач, картайгач ни кала? Мыштым гына каш астыннан карап йөргән малайлардан куркам мин. Чаттан торып берәр этлек эшләп, җанны өшетерләр сыман. Әдәбият ачык йөрәкле (душа нараспашку) затларны ярата.

Туфан МИҢНУЛЛИН, 1983 ел.

Шагыйрь зур шигърият юлына килеп чыккан. Иң авыр, иң олы каршылыклар туплаган юлга аяк баскан. Талант һәм каһарманлык – иң күп сорала торган юл ул... Бу гасырның башында Тукайлар атлаган юл! Гасырның ахырында, инде гасыр тәмамланып килгән чагында, Тукайча әнә шундый кыю аһәңле яшьләрнең ул юлны дәвам итүе – татар укучысына гына түгел, ә тулаем татар милләтенә дә зур куаныч!

Мансур ВӘЛИЕВ, 1990 ел.

ҮЗЕ ТУРЫНДА БЕР ШИГЫРЬ

* * *

Хат язган ул төнәгенәк:
"Син миңа беркем түгел!"
Көлсәң көл, еласаң ела...
Һичьюгы – егыл да үл!

Йолкып атыйм йөрәктән, дип
Кулым түшемә тигәч,
Сизендем – йөрәгем күптән
Аны эзләргә киткән.

Әкрен генә иңләгәндә
Ике каен арасын
Буш күңелем белән тоям
Аның сары карашын.

Йөрәгемне тиргәп барам,
Йөремсәк шул, биләмче...
Урап кайтыр микән инде
Кара күзләр килгәнче...

Бер йолдыз дерелди тышта,
Өшүе ишетелә...
Нишлим соң – хәтта алтмышта
Бер кем буласым килә.

ҮЗЕ ТАРАФЫННАН БАШКАЛАР ТУРЫНДА МӘЗӘК ХӘЛЛӘР

КЕМ АЛДАН ӨЛГЕРЕР?

Азнакайда әдәбият көннәрен үткәреп кайткан Казан язучылары шаккатып сөйлиләр: анда Сөембикә, Болгар, Солтангалиев, Мәхмүт Хәсәнов урамнары бар икән. Әмма төп урам һаман элеккечә – Ленин исемен саклый, имеш.

– Төп урамга исем эзләп табу авыр, – дигән хакимият җыелышында Азнакайның мәдәният министры Азат Галимов. – Әллә соң якташыбыз Марсель Галиевнең "өлгереп" җитүен көтәбезме?

Аның бу сүзеннән соң зал сәер бер тынлыкка чума.

Шунда ялгышканын аңлап алган Азат Галимов:

– Уйлашыйк, җәмәгать. Безнең хакимият башлыгы Әнәс Исхаков та шагыйрь бит әле... – дигәч, зал җиңел сулап куя.

ГОРУРЛЫК

Колшәриф мәчетен ачу тантанасында язучы Марсель Галиев белән артист Хәлим Җәләй янәшә туры киләләр. Инде мәчет ачылган, догалар укылган, чыгышлар ясалган, тик халык таралмый. Президентның һәм чит ил кунакларының чыкканын көтәләр. Күз тутырып карап каласылары килә, кайберәүләрнең, җае килсә, орынып алырга да исәпләре юк түгел.

Менә Президент күренә, министрлар, мөфтиләр... Аларны киң җилкәле таза-таза егетләр урап алган. Шулар, халыкны ике якка аерып, тере коридор ясый.

Шул коридордан үткәндә, Президент Хәлим Җәләйне күреп ала да якын килеп кул бирә, хәл-әхвәлен сораша. Аның шундый гадәте бар!

Каушап калган Җәләй: "Әйбәт, Минтимер Шәрипович, әйбәт, Минтимер Шәрипович", – дип кабатлый. Президент саубуллашып китә, аңа ияргән кәттә түрәләр дә Җәләйгә һәрберсе кул биреп үтә.

Ә Марсель Галиевка игътибар итүче дә юк! Ачу килә, билгеле. Ул, аяк очына басып, башын өскә чөйгән Җәләйгә кызганып карап тора да:

– Сине кем беләндер бутадылар, ахрысы... – ди.

Җәләй исә, Марсельгә теләр-теләмәс горур борылып, Камал театры артистын кем белән бутап булсын, янәсе, теш арасыннан сүзен сөзеп чыгара:

– Минекедәй ямьсез чырай, җаным, республикада берәүдә дә юк! Бутамый торсыннар иде әле!

Марсель Галиев, көлә-көлә, Җәләйне кыяфәте белән өр-яңадан тәбрик итә. Әмма эчтәге гарьлек әле бетмәгән... Парны чыгарасы килә. Андый чакта форсат тиз табыла бит ул. Янәшәдә берәүнең, мәчет гөмбәзен ошатмыйча: "Нигә чиркәүнеке кебек зәңгәр иткәннәр инде..." – дип сөйләнүен ишетүгә, Марсель Галиев аңа тилгән кебек ташлана:

– Зәңгәр түгел ул, мокытым, фирүзә – без мөэмин-мөселманның яраткан төсе! – дип, теге бичараны "нигәйттем" көненә калдыра.

Шуннан соң, канәгатьләнеп, Хәлим Җәләйнең чыраена тагын бер карап, рәхәтләнеп көлеп куя.

...һәм Алмаз ХӘМЗИН тарафыннан бер мактау сүзе:

Ркаил хәтле безнең ил:
Алышсалар әгәр бил,
Холыклары – нольгә-ноль.
Гаделлектә – батыр Ркаил!

Мидхәт САДЫЙКОВ



Шулай бервакыт минем хатынга – Тәслимәгә туй алып барырга тәкъдим ясаганнар.

– Әтисе, ничек уйлыйсың, ризалашыйкмы? Алиянең, дүртенче сыйныфта укучымның әтисе бик үтенеп сорый бит. Олы уллары институтны бетергән, өйләнә икән...

– Алай бик үтенеп сорагач, ризалашыйк, – дидем мин артык уйлап тормыйча. Ул заманда да тамада булгандыр, тик ул эшне мәҗлескә чакырылган бер җор телле кешегә йөклиләр иде дә, шуның белән вәссәлам. Алай акча биреш-нитеш юк иде. Шул бер җылы сүз – рәхмәткә инде. Әмма бәйрәм бәйрәм булып кала, һәм үзенә күрә кызык та, истәлекле дә була иде.

Ярар, хуш, сораганнар икән, әзерләнергә кирәк бит. Ике атна буе мәҗлестә җырлана торган җырларны барлап, үзебезгә күрә репетицияләр ясап чыктык. Заманында икебез дә университет ансамблендә биегәнгә күрә мондый шөгыль безнең өчен таныш күренеш инде. Мин баянда уйныйм, хатын җырлый. Болар өстенә ул әллә ничә шигырь дә ятлады, такмазалар өйрәнде.

Ике атна дигәнең үтте дә китте. Без адресы күрсәтелгән фатирга җыелдык.

Кода-кодача тиешле кешеләре – Мөслим ягыннан, чи татарлар булып чыкты. Үзләре дә җыр-биюгә, мәзәк сөйләргә маһир халык икән. Бераз "кызып" та алгач, дилбегә теге якка күчте. Котлап сүз әйтүләр дисеңме, җырлап күрсәтүләрме...

Әнә шулай бергә-бергә уйнап-көлеп җырлы-моңлы мәҗлеснең беренче өлешен ерып чыктык. Алга таба тәнәфес игълан итеп урамга таралыштык. Биибез. Тик кияү белән кәләш кенә нигәдер уенга соңладылар кебек. Шактый вакыт күзгә чалынмадылар. Баксаң, кәләшне урлаганнар икән. Кодалар ягыннан кунак булып килгән бер эшкуар оештырган моны. Имеш, алар туйга бер миллион сум акча салалар икән (инфляция чоры булса да, зур сумма инде), шуңа күрә булачак киленне сатып алуларын телиләр, имеш. Инде тәнәфескә дигән вакыт та узып китте. Кунаклар да биеп арыды.

Бераздан безнең янга кияүнең әтисе килде.

– Тавык та, бер ярты да алып барып карадым (талон, карточка заманы иде бит), риза түгелләр. Акча сорыйлар.

– Ә кияү кайда, ул нәрсә ди?

– Нәрсә дисен, ике тапкыр чакырып караган да, тегесе чыкмагач, әнә теге почмакка барып утырган. Эндәшми дә сөйләшми дә.

Әлеге диалог өстәл тирәсендәгеләрнең дә игътибарын җәлеп итте.

– Берәр нәрсә булдымы әллә дип сорады тельняшкалы егет. Алар Мөслимнән килгән абзый белән әфган сугышы турында сөйләшеп утыралар иде.

– Нәрсә булсын, әнә... – дип ситуацияне аңлатып бирделәр аңа.

– Әйдәле, барып килик әле, – диде тельняшкалы егет кияүнең әтисенә. Алар тиз-тиз атлап каршыдагы тугыз катлы йортка юнәлделәр. Мин дә, бераз арткарак калышып, аларга иярдем. Тик... мин өскә таба йөгерә-атлый менеп килгәндә тегеләр инде киленне "азат" итеп төшеп тә киләләр иде. Туктап, аларны уздырып җибәрдем. Аннары, тагын берничә адым ясап, өченче кат мәйданчыгында сәер бер күренешне күреп өнсез калдым. Ике бүлмәле фатирның ишеге умырып алынганны, каерылганны, аңлашылмый. Ул яртылаш ачылып, ямьсез кыйшаеп, астагы элмәгендә генә эленеп тора иде...

Шактый озын тәнәфестән соң мәҗлесне башлап җибәрдек. Эшкуар кунак, сәбәп тапкан булып, Мөслимгә үк кайтып киткән. Тагын ике парның урыны бушап калган. Алар урынына "мәҗлес герое" – тельняшкалы егет кереп утырды. Хуҗа абзый аны: "Кунагыбыз – Илдар, Әфган сугышында катнашкан десантчы егет", – дип таныштырды. Кыска гына паузадан соң, мин баянда "Алмагачлар" көен сыздырып җибәрдем, хатын җырлый. Тик дәррәү итеп күтәреп алучылар гына булмады, бер-ике кеше безгә кушылып җырлагандай итте дә, бу номер шуның белән сүнде. Кунаклар кайнар итле-бәрәңге ашарга гына керешкән иде, тельняшкалы егет – Илдар үзе сүз башлады. Әүвәл бер-ике җөмлә белән яшьләрне котлап үтте. Аннары:

– Чыннан да, илгә яшь алмаш, патриотлар кирәк. Сез дә матур-матур балалар, чын ир-атлар үстерегез, – дип теләкләрен ирештерде. – Без инде үз вазыйфабызны үтәдек, – диде ул, сүзен дәвам итеп. – Әйе, күпме яшь гомерләр өзелде шул әфган җирендә. Әйдәгез, аларны искә алып... Мәҗлеснең икенче өлеше әнә шулай патриотик тәрбия темасына борылып китте. Күз күрмәгән, колак ишетмәгән "кайнар" вакыйгалар беренче карашка кызык булып тоелса да, торабара туйдырды. Алга таба командирлар, замполитлар өчен дә тостлар әйтелде, рюмкаłар зеңгелдәп кенә торды. Ир-атларның беришеләре исерешеп бетте. Аларны хатыннары җайлап, көенә барып дигәндәй, өйләренә алып китә торды. Беришеләре, атакага күтәрелергә талпынып караган сугышчылар сыман, үзаларына һаман нидер сөйләнәләр иде...

Без дә бурычны үтәп, шулай дисәң дә ярыйдыр, кайтырга җыена башладык. Хуҗа абзый безне озата чыкты.

– Бик зур рәхмәт инде сезгә, – диде ул. Аннары:

– Дөресен әйтим, күчтәнәч итеп бирергә әйбер дә калмады. Ярар, бер бәхилләтермен әле, – диде уңайсызланып.

– Зарар юк, – дип, без аерылыштык.

Кай арада ярты гасыр вакыт узып киткән. Менә без дә лаеклы ялга чыктык. Илдә, дөньяда үләт чире башлангач, күбрәк өйдә утырабыз. Әдәби китаплар укыйбыз. Теге-бу образларга ияреп күңелгә уелып калган хатирәләр яңара. Елаудан йөзенә сөрем буялган кәләш, каерылган ишек күз алдына килеп баса. Бәхетле парлар булып матур гына яшәп яталар микән? Исән-саулар микән барысы да? Шуны беләсе килә.



САТИРА һӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ

1923 елдан чыга.

№ 2 (1915) февраль 2022

Баш редактор:
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ,
Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе
«ТАТМЕДИА»
акционерлык җәмгыяте.

420047, Казан шәһәре,
Академическая урамы, 2

Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.
Журнал
Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.

«Журналга «Почта России» каталогы, яки https://podpiska.pochta.ru онлайн аша язылып алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).

Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» типографиясендә басылды.
Басылып чыгу: 01.02.2022 ел.
Тираж – 3508 Заказ О-0285

Редакциянең адресы: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Белешмәләр өчен телефоннар:
(843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru
Бәясе ирекле

16+

Уйна да, уйла да!

"... КАЗАН, ДӨРТЛЕ КАЗАН"

КОМПОЗИТОР АЛМАЗ ...

... УКУЧЫ

15

"СИН ... ЖИРДӘ МИН БАРЫН"

"... КӨЕ"

3

... СӨНГАТУЛЛИНА

ТИМЕР ӨЙ САКЧЫСЫ

САТИРИК АЛЫМ

ТЕРЕКЛЕКНЕҢ БАШЫ

5

ТӨС һӘМ ТАВЫШКА БӨЙЛЕ ТӨШЕНЧӘ

12

17

ШАГЫЙРӘ САҖИДӘ ...

"БӨДРӘ ..."

АРТИСТКА ГӨЛСЕМ ...

"... ЖИРЕ КИНДЕР ЖИРЕ"

ОЧУЧЫ

"БИК САГЫНДЫМ ... БУЙЛАРЫН"

ПАЛЬМА ЖИМЕШЕ

ЙОКЛАУ УРЫНЫ

"СУТЫЙ"

НОТА

... БАТУЛЛА

14

7

"БУ ТАҢНАР, ...ЛӘР"

"КҮҢЕЛЛЕ ... ИТЕГЕЗ"

16

ХАЛЫК ЖЫРЫ

... ДӘҮЛИ

8

ЧЕБЕННӘН ...(-1) ЯСАУ

11

"... БУЛМАСА, ЙОЛДЫЗ БАР"

КАЛАШНИКОВ АВТОМАТЫ (АББР.)

6

1

"ЧИЯЛЕ ..."

МУЗЫКАНТ РӘШИТ ...

КУӘТЛЕ КОРАЛ КОМПЛЕКСЫ (АББР.)


2

"ЙӨРӘГЕМНЕҢ ... СЕ"

ӘСИРЛЕК (-2)

4







. . .(-1)

13

ЖЫРЧЫ ... ЙОСЫПОВ

10

9

ЧАЯН

Ринат АБЗАЛОВ төзеде.



1. Кабахәтлекнең иң югары дәрәҗәсе?

2. Хәерчелеккә каршы көрәшүче иң төп идарә?

3. Һава торышын төгәл билгеләү өчен синоптикларга нәрсә булыша?

4. Никахлашу өчен иң яхшы вакыт?

5. "Урлау" фигыленең киләчәк замандагы аталышы?

6. Иң куркыныч сплав (эретмә)?

7. Бай булу өчен зур хезмәт хакы алу җитәме?

ҖАВАПЛАР

1. Арттырылган бәяләре белән ЖКХ квитанцияләре артындагы яңа ел котлаулары. 2. Росстат. 3. "Урыны белән" дигән сүз. 4. 70–80 яшь. Кәләшә күч-хәл белән сөйләшә, ә кияү кешә бөтенләй ишетми диярлек. 5. Утыртачаклар. 6. Корычтай мускуллар һәм чуен баш. 7. Юк, тагын кечкенә хезмәт хакы түләү кирәк.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда җыр исемен укыгыз. Журналыбызның 1 нче санындагы чаянвордның тикшерү сүзе – **«БАШКА БЕРНИ ДӘ КИРӘКМИ»**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

Г. БАҺАВЕТДИНОВ (Чаллы)
М. НӘРИМАНОВ (Сарман),
С. ШӘЙХУЛЛИН (Казан).

Җиңүчебез – Казаннан

Сәгыйдулла ШӘЙХУЛЛИН!

БЕЗНЕҢ ВЕРНИСАЖ





Сергей АНДРИАНОВ – матур кыяфәтле һәм яхшы күңелле кеше. Хәтта үзенең карикатураларында тискәре образлар тудырганда да аларга уңай сыйфатлар бирмичә булдыра алмый. Өстәвенә, Сергей Андрианов – бик тыйнак һәм итагатьле кеше. Бу укучы тарафыннан ихтирам ителгән талантлы карикатурачы өчен, бәлки, артыграктыр да. «Чаян»ны аның рәсемнәреннән башка күз алдына китерүе дә кы-ен – алар журнал битләренең бизәге булып торалар. Бу вернисаж – шуның ачык дәлиле.







